ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.09.2019** **№ 1543**

**“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” башкарма комитетның 2018 ел, 13 нче сентябрь, 1999 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2001 ел, 30 нчы декабрь, 197-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” башкарма комитетның 2018 ел, 13 нче сентябрь, 1999 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге карарның 1 пункты рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә һәм 2018 елның 1 нче сентябреннән соң килеп туган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла икәнен билгеләргә;»;

2) 1-5 кушымталарының 1.2 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«база оклады (вазыйфаи база оклады), хезмәт хакы оклады – минималь оклад (вазыйфаи оклад), эшче яки хезмәткәр вазыйфасы буенча үз һөнәри эшчәнлеген тормышка ашыручы, билгеле һөнәри квалификация төркеменә кергән, компенсацияләрне, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, дәүләт һәм муниципаль учреждение хезмәткәре хезмәт хакы ставкасы;»;

3) 1-5 кушымталарының 1.2 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оклад (вазыйфаи оклад) – хезмәткәрнең аерым бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәгән өчен, календарь айга, компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча билгеләнгән хезмәтенә түләү оклады;»;

4) 1 нче кушымтаның 6.4 пунктының 1 абзацын, 6.1 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«зарарлы һәм (яки) куркыныч эш шартлары белән бәйле эшләрдә мәшгуль булган хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү;»;

5) 2 нче кушымтаның 6.4 пунктының 1 абзацын, 6.1 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«зарарлы һәм (яки) куркыныч эш шартлары белән бәйле эшләрдә мәшгуль булган хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү;»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат- телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында” Интернет мәгълүмат- телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин